| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>ГОРОДСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

2025 елның 1 апреленнән — Балык Бистәсе штп. — № 251

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләренә ярашлы рәвештә, «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсенең 1 нче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы «Балык Бистәсе шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлегенең Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Балык Бистәсе штп., Ленин урамы, 48А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында, шулай ук Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Җитәкче — М.В. Мәгыйзов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Балык Бистәсе
шәһәр җирлеге Башкарма
комитетының 2025 елның 1
апрелендәге 251 номерлы
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында
Нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) «Россия Федерациясендә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшләнде.

1.2. Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибен билгели (алга таба – җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы парковкалар реестры).

1.3. Гомуми файдаланудагы әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып баруның төп максаты – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкаларның бердәм базасын булдыру.

2. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар реестры эчтәлеге

2.1. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар реестры әлеге Нигезләмәгә кушымта нигезендәге рәвеш буенча алып барыла һәм түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

гомуми файдаланудагы парковка урнашкан урынның факттагы адресы;

гомуми файдаланудагы парковканың геолокация координатлары;

гомуми файдаланудагы парковканы билгеләнеше (даими яисә вакытлыча саклау өчен);

гомуми файдаланудагы парковканың төре (түләүле яисә түләүсез);

гомуми файдаланудагы парковканың эш режимы;

гомуми файдаланудагы түләүле парковкадан файдаланган өчен түләү күләме;

гомуми файдаланудагы парковканың сыйдырышлылыгы (транспорт чаралары типларына бүленгән парковка урыннары саны);

"Инвалид"танып белү билгесе урнаштырылган автомобильләрне кую урыннары саны;

били торган җир кишәрлеге мәйданы;

җир кишәрлегенең кадастр номеры.

## 3. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе

3.1. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитетының әйдәүче белгече алып бара.

3.2. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар реестры электрон рәвештә алып барыла, электрон йөрткечтә саклана.

3.3. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларында парковкалар реестрына кертү өчен нигез булып инвентаризация процессында парковкалар урнаштыру яисә ачыклау тора.

3.4. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында парковкалар турында мәгълүматлар гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларында парковкалар реестрына парковканы урнаштырган яисә инвентаризация үткәрү процессында аны ачыклаган көннән алып биш эш көне эчендә кертелә.

3.5. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында парковкалар реестрына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү парковкалар урнаштырылган яисә алар ачыкланган саен гамәлгә ашырыла.

3.6. Гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Балык Бистәсе шәһәр җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары гамәлгә ашыра.

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестрын алып бару тәртибе турында Нигезләмәгә кушымта

## Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Балык Бистәсе шәһәр җирлеге территориясендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларында парковкалар реестры

| № п/п | Гомуми файдаланудагы парковка урнашкан урынның чынбарлык-тагы адресы | Гомуми файдаланудагы парковканың геолокация координатлары | Гомуми файдаланудагы парковканың билгеләнеше (даими яисә вакытлыча саклау өчен) | Гомуми файдаланудагы парковка төре (түләүле яисә түләүсез) | Гомуми файдаланудагы парковканың эш режимы | Гомуми файдаланудагы түләүле парковкадан файдаланган өчен түләү күләме | Гомуми файдаланудагы парковканың сыйдырышлылыгы (транспорт чаралары типларына бүленгән парковка урыннары саны) | "Инвалид" танып белү билгесе урнаштырылган автомобильләрне кую урыннары саны | Били торган җир кишәрлеге мәйданы | Җир кишәрлегенең кадастр номеры |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | |